ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2021 Казан ш. № 422-110/кс-2021

«Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе өчен эчә торган суга 2022-2026 елларга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе (алга таба – «Казан дәүләт казна дары заводы» ФКП) өчен эчә торган суга әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. 2022-2026 елларга «Казан дәүләт казна дары заводы» ФКП өчен эчәргә яраклы суга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы

җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
01.12.2021 № 422-110/кс-2021
карарына 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Казан дәүләт казна дары заводы» ФКП өчен эчә торган суга 2022-2026 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу белән шөгыльләнүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «Казан дәүләт казна дары заводы» ФКП (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча күрсәтелә) | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 34,39 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 36,61 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 36,61 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 37,77 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 37,77 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 38,72 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 38,72 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 39,94 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 39,94 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 40,96 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
01.12.2021 № 422-110/кс-2021
карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Казан дәүләт казна дары заводы» ФКП өчен эчә торган суга 2022-2026 елларга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелегә күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | | | | | | | |
| 1.1 | «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе | 2022 | 23 860,88 | X | - | 6,99 | 1,65 |
| | | 2023 | X | 1 | - | 6,99 | 1,65 |
| | | 2024 | X | 1 | - | 6,99 | 1,65 |
| | | 2025 | X | 1 | - | 6,99 | 1,65 |
| | | 2026 | X | 1 | - | 6,99 | 1,65 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге